**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) 2026 һәм 2027 елларда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алучыны билгеләү турында**

«Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыруны дәвам итү максатында **карар бирәм:**

1. «Иннополис университеты» автоном коммерциячел булмаган югары белем бирү оешмасын «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) 2026 һәм 2027 елларда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алучы дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 196 154,4 мең сум (шулардан: 2026 елда – 84 979,2 мең сум, 2027 елда – 111 175,2 мең сум) дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

2026 һәм 2027 елларда субсидия бирү тәртибен расларга;

субсидиянең максатчан кулланышын контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 27 декабрь
№ 1092